**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№92** **24 апрель 2018 ел**

**«Җир салымы» турында 2014 елның 12 ноябрендәге 146 номерлы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлеше 31 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Җир салымы» турында 2014 елның 12 ноябрендәге 146 номерлы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы карарына (2015 елның 10 сентябрендәге 181 номерлы, 2017 елның 25 сентябрендәге 72 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Салым ташламаларына хокуклы физик затлар, шул исәптән салымнар һәм җыемнар турында законнарда билгеләнгән салым исәбе рәвешендә салым түләүчеләр салым органына үзләренең сайлавы буенча салым ташламасы бирү турында гариза, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документларны тапшырырга хокуклы».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **М.Х. Туктаров**